КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 5 сентябрь г.Казань № 661

Йөклелек буенча исәпкә басканда көндезге бүлектә белем алучы хатын-кызга бер тапкыр бирелә торган түләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарга социаль ярдәм» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 296 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Йөклелек буенча исәпкә басканда көндезге бүлектә белем алучы хатын-кызга 100,0 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән Йөклелек буенча исәпкә басканда көндезге бүлектә белем алучы хатын-кызга бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибен расларга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

йөклелек буенча исәпкә басканда көндезге бүлектә белем алучы хатын-кызга бер тапкыр бирелә торган түләү бирү эшен оештырырга;

йөклелек буенча исәпкә басканда көндезге бүлектә белем алучы хатын-кызга бер тапкыр түләү бирү турындагы мәгълүматны «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыруны тәэмин итәргә. Әлеге мәгълүматны «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыруны (аннан алуны) «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырырга.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасын эшләп бетерүне тәэмин итәргә.

5. Йөклелек буенча исәпкә басканда көндезге бүлектә белем алучы хатын-кызга

бер тапкыр бирелә торган түләү бирүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында әлеге максатлар өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 5 сентябрь, 661 нче
карары белән расланды

Йөклелек буенча исәпкә басканда көндезге бүлектә белем алучы хатын-кызга бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип йөклелек буенча исәпкә басканда көндезге бүлектә белем алучы хатын-кызга бер тапкыр бирелә торган түләү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган түләү) бирү механизмын билгели.

Бер тапкыр бирелә торган түләүне алу хокукы Россия Федерациясе гражданы булган, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәгән, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алган, дәүләт медицина оешмасында йөклелек буенча исәптә торган йөкле хатын-кызга (алга таба – йөкле хатын-кыз) бирелә.

Бер тапкыр бирелә торган түләү йөкле хатын-кызның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре буенча бурычы булмау шарты белән бирелә.

2. Белем бирү оешмасында белем алу урыны буенча академик ялда булган йөкле хатын-кыз (академик ял бирү шартларына бәйсез рәвештә) көндезге бүлектә белем алучылар рәтенә керә.

3. Бер тапкыр бирелә торган түләү, әгәр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча, гариза бирүченең банкта яки башка Россия кредит оешмасында ачылган шәхси исәп-хисап реквизитларын күрсәтеп, бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү турында гариза (алга таба – гариза), теркәлә торган документлар белән бергә, йөклелек срогы 12 атна тулган датадан иртәрәк булмаган вакытта һәм бала тудыру датасыннан соңга калмыйча бирелгән булса, билгеләнә.

4. Бер тапкыр бирелә торган түләү бала тапканнан соң мөрәҗәгать иткән очракта билгеләнми.

5. Бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү гариза бирүченең яшәү урыны буенча «Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлекләре (алга таба – Үзәк бүлеге) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6. Бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү өчен йөкле хатын-кыз яки аның тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) Үзәк бүлегенә гариза белән бергә түбәндәгеләрне тапшыра:

бирелү датасы гариза бирү көненә 30 календарь көннән артмаган һөнәри белем бирү оешмасында һәм югары белем бирү мәгариф оешмасында көндезге бүлектә белем алу факты турында белешмә кәгазе күчермәсен;

бирелү датасы гариза бирү көненә 30 календарь көннән артмаган, йөклелек срогы күрсәтелгән дәүләт медицина оешмасында йөклелек буенча исәпкә кую

турында белешмә кәгазе күчермәсен;

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турында суд карарының закон көченә кергән күчермәләре – Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлмәгәндә;

вәкаләтле затлар өчен ышанычнамә күчермәләре.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар, төп нөсхәләре күрсәтелеп, Үзәк бүлеге белгече тарафыннанраслана.

Гариза почта аша җибәрелгәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.

Гариза бирүче Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать иткәндә шәхесне раслый торган документны күрсәтә.

7. Гариза һәм бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү һәм алу өчен кирәкле документлар (белешмәләр), «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы) файдаланып, электрон рәвештә җибәрелергә мөмкин (техник мөмкинлек булганда).

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша гариза бирү гади электрон имза кулланып башкарыла.

Әгәр гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталыннан файдаланып электрон документ формасында бирелгән булса, гариза бирүче Үзәк бүлегенә гариза теркәлгән көннән алып өч эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны тапшыра.

Гаризаны теркәү журналына теркәү Үзәк бүлегенә кергән көнендә теркәлә.

8. Үзәк бүлеге вәкаләтле оешмалардан түбәндәге белешмәләрне ведомствоара рәсми сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып электрон рәвештә ала:

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү факты турында;

гомуми белем бирү оешмасында белем алу турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычы булу (булмау) турында;

шәхесне таныклый торган документның гамәлдә булуы турында.

9. Үзәк бүлеге гаризаны теркәү журналында теркәгән көннән алып 10 эш көне эчендә бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү турында йә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм әлеге карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

10. Бер тапкыр бирелә торган түләү бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән затның мөрәҗәгате;

әгәр гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталыннан файдаланып электрон документ рәвешендә бирелгән булса, әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны, шул исәптән теркәү

журналында гариза теркәлгән көннән алып өч эш көне эчендә тапшырмау;

йөкле хатын-кызның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү буенча бурычлары булу;

дөрес рәсмиләштерелмәгән документларны тапшыру яки тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүматлар булу;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән бер тапкыр бирелә торган түләү өчен мөрәҗәгать итү срокларын үтәмәү.

11. Гариза бирүчеләрнең банкларда һәм башка кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына бер тапкыр бирелә торган түләүне күчерү «Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү турында карар кабул ителгән айдан соң килә торган айның 25енә кадәр гамәлгә ашырыла.

12. Гариза бирүче тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алардагы документларның төп нөсхәсе өчен җавап бирә.

Нигезсез алынган бер тапкыр бирелә торган түләүне кире кайтару гариза бирүче тарафыннан ирекле рәвештә башкарыла, әгәр гариза бирүче ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартса, ул Россия Федерациясе законнары нигезендә түләтелә.

13. Үзәк бүлеге, документларның чынлыгына һәм тапшырылган белешмәләрнең дөреслегенә шик туган очракта, бирелгән вәкаләтләр чикләрендә гариза бирүче тарафыннан бирелгән белешмәләрне өстәмә тикшерә.

14. Үзәк бүлеге гаебе белән үз вакытында алынмаган бер тапкыр бирелә торган түләү чикләнмәгән срок эчендә түләнә.

15. Бер тапкыр бирелә торган түләү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

___